**СОВЕТ ЛАИШЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

422610 г.Лаишево,
ул. Первомайская, д.39
тел: (8-84378) 2-51-51
факс: (8-84378) 2-55-55

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЛАЕШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН СОВЕТЫ**

422610 Лаеш ш.,
Беренче май урамы, 39 нчы йорт,
тел: (8-84378) 2-51-51
факс: (8-84378) 2-55-55

---

**№ 75-РС** **2019 елның 14 октябреннән**

# РЕШЕНИЕ

# КАРАР

**Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Пәрәү авыл җирлеге Генераль планын раслау турында**

Территориянең тотрыклы үсешен тәэмин итү, инженерлык, транспорт һәм социаль инфраструктураны үстерү, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 9, 24, 25 статьялары, 2003 елның 6 октябрендәге 131 номерлы Федераль законның 14, 15 статьялары нигезендә гражданнар һәм аларның берләшмәләре мәнфәгатьләрен исәпкә алуны тәэмин итү максатларында - № 98-ТРЗ «Татарстан Республикасында шәһәр төзелеше эшчәнлеге турында» 2010 елның 25 декабрендәге 98-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 10 статьясында, 2019 елның 10 сентябрендәге ачык тыңлауларны үткәрү нәтиҗәләре турында бәяләмәне исәпкә алып,Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Пәрәү авыл җирлегенең генераль планын расларга (кушымта).
2. Әлеге карарны «Кама ягы» газетасында, Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәренең Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында түбәндәге адрес буенча бастырып чыгарырга (игълан итәргә): http://pravo.tatarstan.ru һәм Лаеш муниципаль районы сайтында Интернет мәгълүмати-телекоммуникацион челтәренең веб-адресы буенча: http://laishevo. tatarstan.ru.
3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан (халыкка игълан ителгән) көненнән үз көченә керә.
4. Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Пәрәү авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Пәрәү авыл җирлегенең генераль планын раслау турында» 2017 елның 25 маендагы 46 номерлы карары әлеге карар үз көченә кергән көннән үз көчен югалткан дип танырга.
5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны җирдән файдалану, төзелеш, төзекләндерү һәм экологик куркынычсызлык мәсьәләләре буенча Лаеш муниципаль районы Советының даими комиссиясенә йөкләргә.

**Район Башлыгы Урынбасары**
**муниципаль район Советы Аппараты җитәкчесе** **Т. П. Борһанова**